**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Вязовка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Вязовка поселогы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2024 елның 25 ноябре, № 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Вязовка поселогы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Вязовка авыл җирлеге»

карар кылды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Вязовка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә.
Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Вязовка бистәсендәге юлны чокырларга ремонт ясау кысаларында ВКПС сатып алу һәм түгү)

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районының**
**«Вязовка авыл җирлеге "**
**муниципаль берәмлеге башлыгы А. Г. Томский**